ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына:

2.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен, алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, шулай ук сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча сайлау кампанияләре барышында гражданнар җыеннарында Татарстан Республикасы халкыннан кергән наказларны һәм тәкъдимнәрне карау эшен системалы нигездә дәвам итәргә.

2.2. Депутатларга беркетелгән сайлау округларында Россия Федерациясендә Укытучы һәм остаз елы һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында үткәрелә торган чараларда актив катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына:

3.1. Татарстан Республикасында профильле иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлекне, шул исәптән аларның эшчәнлегенә һәм гражданнарның мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне законнар нигезендә хәл итү өлешендә, активлаштырырга.

3.2. Комитетлар карамагындагы актуаль, шул исәптән контроль, мәсьәләләр буенча республика законнарын һәм федераль законнарны мониторинглауны дәвам итәргә.

3.3. Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары белән берлектә федераль

бюджет акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы икътисадына финанслауның өстәмә күләмнәрен җәлеп итү буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын үткәрү буенча эшче төркемнәрнең эшчәнлеге кысаларындагы эшне дәвам итәргә.

3.4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатлары белән комитетлар карамагындагы мәсьәләләр буенча эшне һәрьяклап активлаштырырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында актуаль проблемаларны хәл итү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативаларын кертү хокукыннан активрак файдаланырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 23 декабре
№ 1791-VI ДС